Исполнительный комитет
Бизякинского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
ул. Центральная д. 46, с. Бизяки
Менделеевский район, 423648

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә
авыл җирлеге башкарма комитеты
Үзәк урамы, 46, Бәзәкә авылы,
Менделеевск районы, 423648

тел./факс (85549)3-47-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 25 августы № 65

Бәзәкә авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге территориясендә
экологик агарту һәм экологик культура
формалаштыру турында
нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **КАРАР БИРӘ**:

1. Бәзәкә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агарту һәм экологик культура формалаштыру турындагы Нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе И.И.Кәшәфетдинов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы

Бәзәкә авыл җирлеге
башкарма комитетының
2023 елның 25 августындагы
11 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агарту һәм экологик культура формалаштыру турындагы нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты (яисә 15 статьяның 1 өлешендәге 9 пункты), 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законның 74 статьясы нигезендә эшләнгән һәм экологик агартуны гамәлгә ашыруның хокукый һәм оештыру нигезләрен, « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә экологик культураны булдыру өчен шартлар тудыруны билгели.

## 2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр

2.1. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) экологик мәгълүмат - әйләнә-тирә мохитнең, аның компонентларының торышы турында, әйләнә-тирә мохитне һәм табигать ресурсларын пычрату чыганаклары яисә әйләнә-тирә мохиткә башка зарарлы йогынты ясау турында, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау, яклау һәм торгызу чаралары хакында белешмәләр;

2) экологик культура - социаль мөнәсәбәтләр системасын, мораль кыйммәтләр, кеше һәм җәмгыятьнең әйләнә-тирә мохит белән үзара хезмәттәшлеге нормаларын һәм ысулларын үз эченә алган дөньякүләм һәм милли мәдәниятнең аерылгысыз өлеше;

3) экологик агарту - экологик иминлек турында экологик белемнәр, әйләнә-тирә мохитнең торышы турында мәгълүмат тарату һәм экологик культураны булдыру, табигатькә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану максатларында табигать ресурсларыннан файдалану турында.

4) экологик туризм - табигать мохитенә зарар китерми торган ял оештыру һәм табигый фәнни яисә гамәли белем һәм тәҗрибә алу максаты булган табигать тарафыннан юнәлешле туристлык эшчәнлеге.

## 3. «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуның һәм экологик культураны булдыруның

**төп принциплары**

3.1. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агарту һәм экологик культура формалаштыруның төп максатлары:

1) Бәзәкә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә табигатькә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру һәм экологик культураны арттыру;

2) уңай әйләнә-тирә мохитне, биологик төрлелекне һәм табигать ресурсларын саклап калу.

3.2. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуның һәм экологик культура булдыруның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә халыкны мәгълүмати тәэмин итү;

2) экология-агарту үзәкләре буларак махсус саклanучы табигать территорияләренең ролен күтәрү;

3) « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә экологик әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнашуга гражданнарны, иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларны җәлеп итү;

4) « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балаларны, яшьләрне һәм башка социаль төркемнәрне әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә экологик юнәлешле эшчәнлеккә җәлеп итү;

5) « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә экологик туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

6) калдыклар белән эш итүгә, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны аерым-аерым җыюга җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру.

## 4. "Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә экологик агартуның һәм экологик культура формалаштыруның төп принциплары

4.1. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә экологик агартуның һәм экологик культура булдыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

1) экологик агартуның системалылыгы һәм өзлексез булуы;

2) экологик агартуның гомумилеге;

3) экологик мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

4) экологик агартуның « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерүгә юнәлдерелгән булуы, Бәзәкә авыл җирлеге өчен актуаль булган чишелеш, экологик проблемалар, табигатьне саклау - әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын яхшырту;

5) җирле үзидарә органнары тарафыннан экологик агарту һәм экологик культура булдыру өлкәсендәге чараларны эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда хәбәрдарлык.

## 5. Экологик агарту һәм экологик культураныформалаштыру өлкәсендә гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның хокуклары

5.1. Экологик агарту һәм экологик культура булдыру өлкәсендә гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) экологик агарту, экологик культура булдыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

2) муниципаль программалар проектларын һәм экологик агарту буенча планнарны эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда иҗтимагый (гавами) тыңлауларда катнашу юлы белән катнашырга;

3) экологик агарту эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле дөрес экологик мәгълүмат соратып алырга һәм билгеләнгән тәртиптә алырга;

4) интерактив белем бирү технологияләрен, күргәзмәләрне һәм экологик программаларны һәм укыту-агарту материалларын тәкъдир итүне гамәлгә ашырырга;

5) халыкның хокукый һәм экологик культурасын булдыру һәм арттыру максатыннан шимбә өмәләре оештырырга, территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү эшендә, смотрларда, конкурсларда, конференцияләрдә, семинарларда, мәгълүмати һәм башка кампанияләрдә актив катнашырга;

6) законнар нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

**6. Халыкны экологик агарту**

6.1. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халыкны экологик агарту һәм экологик культура дәрәҗәсен күтәрүнең нигезе буларак, кешенең әйләнә-тирә мохиткә карата әхлакый мөнәсәбәтен формалаштыру максатларында гамәлгә ашырыла.

6.2. Экологик агарту һәм экологик культура булдыру җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, экологик иминлек турында мәгълүмат;

2) махсуслаштырылган радио- һәм телепрограммалар (социаль рекламаны да кертеп), экологик характердагы басмалар чыгару юлы белән, шулай ук « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары мәгълүматын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштыру юлы белән экологик белемнәрне пропагандалау, әйләнә-тирә мохитнең, табигать ресурсларының торышы һәм экологик иминлек турында мәгълүмат тарату;

3) экологик-агарту эшчәнлеге (фәнни-гамәли конференцияләр, форумнар, конкурслар, фестивальләр, күргәзмәләр, экология акцияләре һәм башкалар);

4) экологик туристлык;

5) экологик үзәкләр, табигать музейлары, экология сукмаклары, экология лагерьлары булдыру, шул исәптән, махсус саклау режимын исәпкә алып, региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә;

6) гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка рәвешләр.

**7. «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә музейлар, китапханәләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларының экологик агартуда һәм экологик культура формалаштыруда катнашуы**

7.1. Экологик агарту өлкәсендә музейларның төп эш һәм эшчәнлек төрләре һәм « Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә экологик культура булдыру, экологик юнәлешле экспозицияләр, стационар һәм күчмә күргәзмәләр оештыру, конференцияләр, конкурслар, семинарлар, «түгәрәк өстәлләр» һәм башка чаралар оештыру һәм уздыру.

7.2. Китапханәләр үз уставлары нигезендә « Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә китапханә фондын экологик һәм хокукый характердагы документлар һәм басмалар белән комплектлау, конференцияләр, конкурслар, семинарлар уздыру, «түгәрәк өстәлләр» һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек проблемаларына багышланган башка чаралар уздыру юлы белән экологик агартуда һәм экологик культура формалаштыруда катнаша

7.3. Редакция уставы һәм (яисә) гамәлгә куючы һәм редакция (баш мөхәррир) арасындагы шартнамә нигезендә телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре экологик, экологик-хокукый мәгълүмат тарату, экология, әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик иминлек проблемаларына

багышланган программалар һәм материаллар чыгару юлы белән « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә экологик культураны формалаштыруда катнаша.

7.4. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары экологик культура формалаштыруга ярдәм итә торган махсуслаштырылган телерадиотапшырулар оешмаларын, вакытлы матбугат басмаларын үстерү буенча кирәкле икътисадый һәм оештыру шартларын тәэмин итәләр.

## 8. «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә экологик агарту һәм экологик культура булдыру өлкәсендәге эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү

8.1. « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә экологик агарту һәм экологик культура булдыру өлкәсендәге эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү Бәзәкә авыл җирлегенең җирле бюджеты, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.